

Һәрбер авылда vзенен һонәр осталары булган. Алар – балта осталары, калайчылар, тимерчеләр, тегvчеләр, аш-су осталары...Гасырлар буена нинди генә ашамлык пешермәгәннәр алар. Гаяз Исхакыйнын “Кәжvл читек» әсәрендә дә коймак пешерv турында язылган. Бик борынгыдан килгән коймак пешерv рецепты турында сvзем. Хәзер аны пешерә белvче сирәк. Әмма Кадошкино районы Латышовка авылында шундый кеше яши.

Аш-суга осталык - зур дәрәҗә. Гомер-гомергә авылнын ин унган кешесе аш-суны оста пешергән; ул кайсы йорт кунак жыя, шунда барып табын әзерләшкән. Гадәттә, ул белемне дә, тәжрибәне дә оендә, мич янында туплаган. Ә хәзер исә пешекчеләр әзерли торган уку йортлары бихисап. Аерым тор ризыкны әзерләргә ойрәтvче курслар, мастер-классларнын да исәбе юк. Теләген булсын да, ялкауланма гына! Әмма барыннан кадерле һәм тәмле борынгыдан килгән милли ашларыбыз. Якты кvнелле, оста куллы, бер эштән дә курыкмаган Хаят Хосәен кызы Бикмурзинаны кайнанасы Нәфисә Рамазан кызы vз дә иткән һәм коймакны да борынгыларча пешерегә ул ойрәтеп калдырган. Нинди сон коймак һәм ничегрәк пешерәсез дигән соравыма Хаят ханым:

- Татар халык ашы булган блины, оладьи сvзенен тәржемәсе - коймак. Ә безнен якта нечкәләре, калыннары, чvпрәле һәм содаласы - беленнәр, ә коймак – ул аерым рецепт белән калын иттереп пешерелә торган ашамлык. Мордовия татарлары тv (тары ярмасын тv яртасы дип борынгыдан әйтеп киләләр, аны тоеп он ясаганнар) коймагын пешерә. Аны жиренә житкереп пешерv очен, башта тары ярмасын киледә тоеп, vрә кайнатырга кирәк. Аннары аны аерым технология буенча ачыта һәм чечетә дә белv таләп ителә. Аннан сон гына ике торле он - тары ярмасы һәм бодай оны кушып, тоз-шикәрен, йомыркасын салып соткә изеп камыр ясыйм, дип рецепты белән уртаклашты Хаят Хосәен кызы.- Борынгылар шулай иттереп пешергәннәр. 27 ел элек тv коймагын зур мичтә пешерә башладым, ә хәзер – газ плитәсендә. Бу осталыкка кайнанам Нәфисә Рамазан кызы ойрәтеп калдырды, ә мин кызым Светланага ойрәтәм.

Бер эштән дә курыкмаган Латышовка авылында Сания Гани кызы белән Хосәен Хәсән улы гаиләсендә, дvрт малай белән бергә, Хаят исемле кыз туып-vсә. Туган авылы мәктәбен гел бишле билгеләренә генә тәмамлагач, Инсар шәһәре училищесында бухгалтерлык профессиясен vзләштерә. Хыялында югары белем алу булуына

карамастан, Равиль Хаким улына кияvгә чыга. Гаиләдә ике бала туа. Шул вакыт авыл клубында



берьюлы директор да, китапханәче дә, худрук та булып 9 ел эшләп ала ул. Авыл һәм район кvләмендә торле чаралар vткәргән; vзе шигырьләрне сәнгатьле иттереп яттан сойлгән, авыл ансамблендә жырларга да яраткан. Латышовкада ОАО «Лисма» - Кадошкино электротехник заводы (КЭТЗ) филиалы ачылгач, анда да 3 еллап эшче буларак хезмәт итә ул. Филиал ябылгач, 9 ел авыл кибетендә, “Камок”та, сатучы булып та эшли; белгечлеге буенча бухгалтер бит ул. Татарларда «егет кешегә житмеш торле һонәр дә аз” дисәләр, Хаят Бикмурзина турында да шуны ук әйтә алабыз дип уйлыйм. Чонки тормышта нинди генә эшләрдә эшләргә туры килми язма героема. Янадан Кадошкино КЭТЗсында эшләп алгач, Инсар шәһәре ООО «Ксенон» заводында, vзе әтмешли, гади эшче буларак хезмәт биографиясен бvген дәвам итә. Эштән курыкмый ул; эш батыры.

Хаят Хосәен кызы Бикмурзина гомере буе халыкка яхшылык эшләргә тырыша һәм эшли, изгелектә анын кvнеле һәм тормыш девизы да - булдыра алган кадәр жирдә яхшылып эшләп калу. Гаиләсе очен бар кочен куя. Ике матур баласына – Кәмил белән Светланага, югары белем биреп олы юлга чыгара ул. Балалары да vзенә охшаган, ахры, улы – комеш медаль белән туган авылы мәктәбен тәмамлый, кызы – гел бишле билгеләренә. Әниләренен хыялын тормышка ашырып, икесе дә югары белем ала. Хаят ханым берvзе балаларына тиешле тәрбия бирә, чонки гомере буе туган авылы малларын караучысы булып хезмәт иткән тормыш иптәше Равиль Хаким улы, кызганычка каршы, озакламый (13 ел инде) бакыйлыкка кvчә. Бvген балалары Ковылкино шәһәрендә гаиләләре белән яшиләр; Кәмиле - охранада, Светланасы шәһәр мәгариф бvлеге бухгалтеры булып тырышып эшлиләр. Ике оныгы Линара белән Юлия, әти-әниләре белән Латышовкада яшәvче Хаять әбиләренә еш килеп, хәлен белеп йориләр. Ойләренен ишеге бер дә ябылмый тора. Мона Хаят Хосәен кызынын коймак пешерv остасы булуы да сәбәп. Милли традиция буларак, бvген дә тv коймагын дини бәйрәмнәрдә һәм олылап искә алу кичәләрендә пешереп табынга куялар. Кадерле ашны, ана заказ биреп, тирә-кvрше

авыллары, Инсар һәм Кадошкино татарлар пешертәләр. Заводта хезмәт итvенә карамастан, якташларынын теләген vти, йокылар йокламыйча тонге сәгать бердә булса да, тv коймагын пешерә Хаят ханым Бикмурзина. Кайчак коненә иллене дә, йозне һәм артыграк та пешерергә туры килә ана. Ничек якташлары соралган эшне vтәмәсен, пешерvчеләр юк бит. Менә шундый булдыклы да, игелекле дә кешеләребез яши безнен авылларыбызда.

**Наилә Насырова**